



# Ул Мәрҗаниләр нәселеннән иде...

*Җирдә кеше торса торсын,*
*Эзе калсын тирән булып.*
*Үзе үлсә, эше калсын*
*Мең яшәрлек имән булып.*

**Муса ҖӘЛИЛ.**

Әлеге шигъри юлларны укыгач, тормышта үзләреннән тирән эз калдырган көчле шәхесләр күз алдына килә. Аларның яшәве көчле, дәртле бер җыр булып бар дөньяны шаулата, исемнәре меңләгән кешеләрнең күңелендә чагылыш таба. Мәшһүр татар мәгърифәтчесе, фәлсәфәче, тарихчы, дин әһеле, педагог, археолог, этнограф Шиһабетдин Мәрҗанине, мәсәлән, кешелек дөньясы бүген дә олы хөрмәт белән искә ала. Аның исеме мәңгеләштерелгән, рухи мирасы буыннарга күчә.

Татарстан Республикасының башлангыч белем бирү системасына керткән өлеше белән зур урын алып торган тирән, төпле белемле зат Марат Гайнетдиновның (1939-2011) нәсел шәҗәрәсе татар халкының күренекле шәхесе Шиһабетдин Мәрҗанигә барып тоташуын күпләр белмидер дә әле.

Балаларга мәхәббәт, үз тормышын уку-укыту эшенә багышлау теләге Марат Лотфулла улында үсмер чакта ук сизелә. Моны күңел тартуы, кан тартуы, дип әйтергә була.

Өйрәнүләрдән күренгәнчә, Шиһабетдин Мәрҗани әтисе мәдрәсәсен тәмамлагач, дүрт ел Ташкичү мәдрәсәсендә укыта. Аннан соң Бохара һәм Сәмәркандта белемен баету белән беррәттән, тирә-юнь авылларга чыгып белем бирә.

XIX гасырның икенче яртысында татар мәгърифәтчеләренең яңа агымы барлыкка килә. Әлеге агымның җитәкчесе итеп хаклы рәвештә Ш.Мәрҗанине саныйлар. Нәкъ менә ул, беренчеләрдән булып, мәдрәсәдә укытуга яңарышлар кертә, татар халкының рус һәм чит ил мәдәнияте фәне өлкәсендәге казанышларын өйрәнүне мөһим дип саный.

Укымышлылык, белемгә омтылыш Гайнетдиновлар нәселендә буыннан-буынга күчеп килгән. Казан педагогия институтын тәмамлаганнан соң, Марат Лотфулла улы да үз эшчәнлеген Шәле мәктәбендә директор вазифасыннан башлап җибәрә, аннан Мәгариф министрлыгында эшли. Анда эшләү чоры Марат Лотфулла улының күңелендә тирән эз калдыра. Ул укуукыту эшләрен оештыручы галимнәр Мирза Мәхмүтов, Равил Низамов, Габделхан Габдуллин белән таныша. Зур тәҗрибә туплый. Тынгысыз, көчле рухлы Марат педагоглык эшчәнлеген киңәйтә бара.

Язмыш Марат Гайнетдиновны кайчандыр Шиһабетдин Мәрҗани йөргән юллар белән очраштыра. Ул 1982 елда Казан педагогия көллиятенә директор итеп билгеләнә. Әлеге уку йорты үзенең данлыклы тарихын 1876 елда Казан татар укытучылар мәктәбе буларак башлап җибәрә. Аны оештыручылар арасында Шиһабетдин Мәрҗани, Каюм Насыйри, Владимир Радлов, Ибраһим Терегулов һәм башка күп кенә фән һәм мәдәният эшлеклеләре була.

Нигез ташы ныклы салынган, күрәсең. Бер гасыр ярымнан артык вакыт эчендә Казан педагогия көллияте меңләгән мөгаллимнәр әзерли. Алар арасында күп кенә атказанган укытучылар, галимнәр, мәктәп директорлары, министрлык хезмәткәрләре бар. Марат Лотфулла улы да көллияттә эшләү дәверендә оештыручы һәм мөгаллимлек сәләтенең иң югары ноктасына җитә. Ул көллиятнең үсешенә һәм, гомумән, республиканың башлангыч белем бирү белгечләрен әзерләү системасын үстерүгә зур өлешен кертә. Оештыру эшләре белән бергә гыйльми-тикшеренү юнәлеше үрелеп бара. Күп кенә фәнни хезмәтләре, уку әсбаплары басылып чыга. РСФСРның атказанган укытучысы, педагогия фәннәре кандидаты, доцент, 1982-2005 елларда Казан педагогия көллияте директоры үзенең һөнәри эшчәнлегендә зур абруй казана.

Аның өчен иң зур бүләк – яраткан укучылары. Марат Гайнетдинов булачак укытучыларны рухи-әхлакый яктан тәрбияләүгә зур игътибар бирә. Яшьләр арасында татар телен һәм мәдәниятен саклап калуда, үстерүдә дә Марат Лотфулла улының өлеше зур.

Шушы максат белән ул "Ял көне" клубы оештыра. Әлеге клуб югары культуралы, туган телен, тарихын яхшы белүче татар яшьләрен тәрбияли. Анда студентлар бик теләп йөргәннәр, бәйрәмнәрдә исә ата-аналар да катнашкан. Клубның эшчәнлеген үстерүдә Ш.Мәрҗани исемендәге тарих институтының тарих фәннәре докторлары Г.Дәүләтшин, Р.Әмирханов һәм Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты профессоры Н.Хисамов та ярдәм итә.

Халкына мәхәббәт, хөрмәт, аңа үзенне аямыйча хезмәт итү Марат Гайнетдиновның яшәү мәгънәсе була. Ул тормышта төгәл максатлар куя һәм аларны гамәлгә ашырганда, төпле фикерләре белән кызыксындырып, үз артыннан әйдәп барырга сәләтле кеше иде.

Оясында ни күрсә, очканында шул булыр, - ди татар халкы. Марат Гайнетдинов үзенең 4 баласын тәрбияләүгә дә зур игътибар бирә. Ул укытучы хезмәтенә ихтирам тәрбияли. Табигый ки, аның кызлары Лилия һәм Илмира укытучы һөнәрен сайлыйлар. Ш.Мәрҗани исеме белән бәйле нәсел агачының тамырлары әнә шулай нык һәм тирәндә бүген.

**Резидә ХӘЙРЕТДИНОВА,**
КФУ доценты,
**Ләйсән КАЮМОВА,**
КФУ аспиранты.